| | |
|---|---|
| **СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «МИЧУРИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МИЧУРИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

04 апрель 2025 ел № 6

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2.Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә, схеманы раслаганнан соң биш көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук рәсми сайтта Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча хәбәр итәргә: ТР, Лениногорск муниципаль районы, Мичурин исемендәге поселок, Совет ур., 26 йорт – административ бина, Совет ур., 28 йорт – мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 йорт – мәдәният йорты бинасы, Үзәк ур., 15 йорт – мәктәп бинасы.

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
"Мичурин авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Ә.Иванова

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районының
«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Советының
2025 елның 04 апреленнән 6
номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы**

**1 нче бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 53 кеше

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Мичурин ис. п. урамнары буенча: Дала, Якты, Совет (1-35 йорт)

**2 нче бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 52 кеше

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Мичурин ис. п. урамнары буенча: Совет (36-83 йорт), Урман (20-24 йорт)

**3 нче бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 49 кеше

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Мичурин ис пос. Урман урамы(1дән 19 йорт)

**4 нче бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 62 кеше

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Сережкино авылы Лесная урамы буенча (1 дән 47 )

**5 нче бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 63 кеше

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурино авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Сережкино авылы: Урман (47а-79 йорт), Мәктәп (10 нан 29а га кадәр)

**6 нчы бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 62 кеше

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Сережкино авылы Үзәк урам буенча (3-60 йорт)

**7 нче бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 62 кеше

Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Яңа Сережкино авылы: Совет, Яшьләр, Үзәк (1, 2 йортлар), Мәктәп (1 дән 9 га кадәр йортлар).

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары график сурәте схемасы**




